# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында ветеринария эше турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария эшен оештыруның һәм гамәлгә ашыруның бердәм үзенчәлекләрен билгели.

### I бүлек
### Төп нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасында ветеринария эше

1. Татарстан Республикасында ветеринария эше – җәмгыять ихтыяҗлары өчен ветеринария ягыннан сыйфатлы һәм куркынычсыз терлек продукциясе алу һәм халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан саклау максатларында хайваннарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча комплекслы гамәлләрне тормышка ашыру ул.

2. Татарстан Республикасында ветеринария эше дәүләт ветеринария хезмәте тарафыннан оештырыла һәм ул җитештерүдәге ветеринария хезмәте, ветеринария кооперативлары һәм эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария белгечләре белән берлектә гамәлгә ашырыла.

2 статья. Ветеринария турында законнар

Татарстан Республикасының ветеринария турындагы законнар җыелмасы әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан, Президент әмерләреннән, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының шулар нигезендә чыгарыла торган карарларыннан тора, барлык министрлыклар өчен, милек рәвешләренә һәм кемгә буй-

сынуларына карамастан, барлык предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, шулай ук урындагы затлар һәм гражданнар өчен аларны үтәү мәҗбүри.

3 статья. Ветеринария эшчәнлегенә хокук

Югары яисә урта ветеринария уку йортларын тәмамлаган һәм ветеринария табибе яисә ветеринария фельдшеры белгечлеге алган затларга ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт ителә. Алар дәүләт ветеринария учреждениеләрендә, колхозларда, совхозларда, агрокомбинатларда, агрофирмаларда, крестьян /фермер/ хуҗалыкларында, кооперативларда, ветеринария товарлары җитештерүче кече предприятиеләрдә, балыкчылык, умартачылык предприятиеләрендә, зоопаркларда һәм ветеринария эшчәнлегенә бәйле башка оешмаларда һәм учреждениеләрдә ветеринария буенча вазыйфаларны башкара алалар.

4 статья. Ветеринария эше буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Югары Советы карамагына ветеринария эше буенча түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасында ветеринария эшен законлы көйләү;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсенең ветеринария эше буенча республика һәм җирле органнарын төзү тәртибен һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагына ветеринария эше буенча түбәндәгеләр керә:

– ветеринария эше һәм бу өлкәдә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру буенча норматив-хокукый актлар эшләү һәм аларны кабул итү;

137

- дәүләт ветеринария хезмәтен нигезле оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү;

- йогышлы авырулар үләте килеп чыкканда Татарстан Республикасы территориясендә карантин яисә башка чикләүләр билгеләү һәм аларны гамәлдән чыгару турында карарлар кабул итү;

- ветеринария эше буенча халыкара оешмалар белән, чит ил дәүләтләре белән хезмәттәшлек итү.

3. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары карамагына ветеринария эше буенча түбәндәгеләр керә:

- аерым территорияләрдә, хуҗалыкларда һәм йортларда хайваннар өчен куркынычлы авыруларны бетерүгә юнәлдерелгән карантинны, тиешле шартларны һәм режимнарны билгеләү һәм аларны гамәлдән чыгару;

- терлекчелек фермаларының, комплексларының, терлекчелек продуктларын һәм чималын эшкәртү буенча башка предприятиеләрнең эшчәнлек зонасында тирә-як мохитнең санитар торышын тикшереп торуны оештыру; терлекләрне йогышлы авырулардан, үләттән кисәтү һәм аларны бетерү буенча чараларны гамәлгә ашыру; авырулар нәтиҗәсендә терлекләр үлүне, терлекчелек продукциясен югалтуны һәм аның сыйфаты начараюны киметү буенча чаралар кабул итү;

- ветеринариягә караган әйберләр җитештерү буенча предприятиеләр төзергә булышу һәм аларны киңәйтү;

- хайваннар өчен аеруча хәтәр авыруларга каршы профилактика үткәрүне оештыру буенча һәм аларга каршы көрәш буенча карарлар кабул итү.

## II бүлек

## Дәүләт һәм җитештерү буенча ветеринария хезмәте

**5 статья.** Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтен оештыру

198



1. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенең вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- авыл хуҗалыгы, йорт, зоопарк хайваннарында һәм башка хайваннарда, кошларда, балыкларда, умарта кортларында була торган йогышлы һәм йогышсыз авыруларны кисәтү һәм аларны булдырмау;

- куркынычсыз һәм сыйфатлы терлекчелек продукциясе җитештерүне тәэмин итү буенча ветеринария тикшерүе;

- кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан халыкның сәламәтлеген саклау;

- Татарстан Республикасы территориясен читтән хайваннар арасында була торган йогышлы авырулар керүдән саклау.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте системасына түбәндәгеләр керә:

- Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе;

- районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре.

3. Республикада ветеринария эшенә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе җитәкчелек итә. Ветеринария буенча баш идарәгә: республика ветеринария лабораториясе, "Зооветснаб" Татарстан республика берләшмәсе, республика ветеринария станциясе керә.

4. Районда ветеринария хезмәтенә дәүләтнең район ветеринария берләшмәсе җитәкчелек итә. Дәүләтнең район ветеринария берләшмәсенә: хайваннар авыруларына каршы көрәш буенча район станциясе, ветеринария лабораториясе, ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе, ветеринария буенча участок дәвалау

йортлары, ветеринария бүлекләре һәм пунктлары, ветеринария даруханәләре, шулай ук, кемгә буйсынуларына карамастан, эшкәртүче предприятиеләргә хезмәт күрсәтүче ветеринария белгечләре.

5. Шәһәр ветеринария хезмәтенә дәүләтнең шәһәр ветеринария берләшмәсе җитәкчелек итә. Дәүләтнең шәһәр ветеринария берләшмәсенә: авыруларга каршы көрәш буенча шәһәр станциясе, ветеринария буенча участок дәвалау йортлары, ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясе, шулай ук терлекчелек продукциясен һәм чималын эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә ветеринария тикшерүен башкаручы хезмәтләр.

6. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе башлыгы, районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре башлыклары бер үк вакытта Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы, районнарның һәм шәһәрләрнең баш дәүләт ветеринария инспекторлары булалар.

Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы - Ветеринария буенча баш идарә башлыгы - Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эшкә алына һәм вазыйфаларыннан азат ителә.

Районнарның һәм шәһәрләрнең баш дәүләт ветеринария инспекторлары, Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы белән килешеп, районнарның һәм шәһәрләрнең хакимият башлыклары тарафыннан билгеләнә.

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтенең вәкаләтләре

Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәте карамагына түбәндәгеләр керә:

1. Кемгә буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, дәүләт һәм житештерү буенча ветеринария хезмәтләренең барлык учреждениеләре эшчәнлегенә житәкчелек итү, ветеринария кооперативларының, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче кече предприятиеләрнең һәм ветеринария белгечләренең эшчәнлеген тикшереп тору.

2. Үләткә каршы чараларның һәм ветеринария-санитария гамәлләренең комплексын үткәрү буенча предприятиеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның эшчәнлеген көйләү.

3. Республикада ветеринария эшен үстерүнең төп үзенчәлекләрен һәм төп юнәлешләрен эшләү, аның оештыру рәвешләрен камилләштерү.

4. Терлекләр арасында йогышлы һәм йогышсыз авыруларны булдырмау чараларын күрү; хайваннарны аеруча хәтәр авырулардан саклау буенча республика программаларын эшләү.

5. Йогышлы авырулар үләте килеп чыкканда, хайваннар күпләп йогышсыз авыру белән авырганда Татарстан Республикасы территориясендә карантин яисә башка чикләүләр билгеләү һәм аларны гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр әзерләү.

6. Терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын радиактив, техноген һәм башка зарарлы йогынтылардан ветеринар яклау буенча республика программаларын әзерләү.

7. Колхозларда, совхозларда, башка авыл хужалыгы предприятиеләрендә һәм крестьян хужалыкларында ветеринария-дәвалау эшен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру.

8. Терлекчелектә ветеринар иминлекне тәэмин итү өчен кирәкле биологик препаратларга һәм башка матди-техник әйберләргә республика заказларын булдыру.

201

9. Гадәттән тыш вәзгыятьләрдә үләткә каршы кичектергесез чараларны һәм ветеринария-санитария гамәлләрен үткәрү өчен кирәкле биологик, дәвалау, дезинфикцияләү препаратларының һәм башка матди-техник чараларның республика резервын булдыру һәм аларны бүлү.

10. Терлек авырулары һәм ветеринария чараларының нәтиҗәлелеге буенча ветеринар исәп алып баруны, алар турында хисап тотуны һәм статистик анализ ясауны булдыру.

11. Ветеринария белгечләренә ихтыяҗны билгеләү. Ветеринария белгечләрен аттестацияләүне оештыру һәм үткәрү.

12. Ветеринария белгечләренә Ветеринария эшчәнлеге алып бару өчен рөхсәт бирү, җитештерү лабораторияләренә, цехларга, кече предприятиеләргә һәм аерым гражданнарга ветеринариягә кагылышлы әйберләр ясауга һәм аларны сатуга хокук бирү; ветеринария табибләренә һәм фельдшерларына эшкуарлык эшчәнлеге алып баруга рөхсәт бирү.

13. Терлекчелек предприятиеләренең, фермаларының, ит җитештерү, суыту, консервлау, сөт, күн, йон эшкәртү сәнәгате предприятиеләренең торышына дәүләт ветеринария күзәтчелеге; терлек һәм терлекчелек продуктлары белән сату итүче предприятиеләрнең, җәмәгать туклануы предприятиеләренең, базарларның торышына дәүләт ветеринария күзәтчелеге; терлекчелек фермаларын, эшкәртү предприятиеләрен һәм ветеринария объектларын проектлаштырганда һәм төзегәндә; терлекләрне, терлекчелек продуктларын һәм чималын ташыганда, чит илгә чыгарганда һәм чит илдән кайтарганда дәүләт ветеринария күзәтчелеге; Татарстан Республикасы территориясен Татарстан Республикасыннан читтәге

202

территориялэрдэн хайваннар өчен йогышлы авырулар кертүдэн саклауга дәүләт ветеринария күзәтчелеге.

I4. Терлекчелек продукцияләрен һәм чималын, азык-төлекне һәм аларны ташу җайланмаларын саклау өчен ит, сөт эшкәртү предприятиеләренең, терлек суюу биналарының, ярминкәләрнең, складларның ветеринария-санитария торышын бәяләү.

I5. Терлекчелек продуктларын һәм үсемлектән алынган азык-төлек продуктларын ветеринария-санитария ягыннан һәм экологик яктан тикшереп тору.

I6. Ветеринария мәсьәләләре буенча халыкара ветеринария оешмалары, чит ил дәүләтләре белән хезмәттәшлек итү.

7 статья. Житештерү буенча ветеринария хезмәте, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария кооперативлары һәм ветеринария белгечләре

I. Предприятиеләр, учреждениеләр, колхозлар, совхозлар, терлекчелек комплекслары, житештерү кооперативлары, акционер җәмгыятьләр, агрокомбинатлар, агрофирмалар һәм башкалар үз акчалары исәбенә ветеринария белгечләре тота алалар.

2. Хайваннарга ветеринария хезмәте күрсәтү өчен колхозларда, совхозларда, агрофирмаларда, агрокомбинатларда, крестьян /фермер/ һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында ветеринария кооперативлары төзелергә мөмкин.

3. Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче ветеринария белгечләре төрле милек рәвешендәге терлекчелек хуҗалыкларына ветеринария хезмәте күрсәтәләр.

203

## III б ү л е к

### Дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм житештерү буенча ветеринария-санитария күзәтчелеге

8 статья. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге

1. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге - идарә итү органнарының һәм дәүләт ветеринария хезмәте учреждениеләренең хайваннар авыруларын булдырмауга һәм Татарстан Республикасының ветеринария буенча законнарын бозуга юл куймыйча, бозган очракта, аларны ачу һәм чикләү юлы белән ветеринария-санитария өлкәсендә иминлек тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге ул.

Дәүләт ветеринария күзәтчелеге вазыйфаларына түбәндәгеләр керә:

- хайваннар арасында йогышлы авырулар килеп чыгунын, аларның йогышсыз авыру белән күпләп авыруларының һәм агулануларының сәбәпләрен һәм шартларын ачу һәм билгеләү;

- үләткә каршы чараларның, кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авыруларны булдырмау һәм бетерү буенча гамәлләрне дә кертеп, һәм Татарстан Республикасы территориясен Татарстан Республикасыннан читтәге территорияләрдән хайваннар өчен йогышлы авырулар кертүдән саклау буенча гамәлләрнең тулысынча үтәлүен оештыру һәм тикшереп тору;

- терлекчелек белән шөгыльләнгәндә, йорт, зоопарк хайваннарын һәм башка хайваннарны, кошларны, балыкларны, умарта кортларын асраганда, терлекчелек продукциясен житештергәндә, ташыганда һәм сатканда катгый рәвештә кулланылырга тиешле ветеринария кагыйдәләре, башка норматив актлар эшләү;

- оештыру-житештерү, гомуми профилактика чаралары, үләткә каршы чаралар һәм ветеринария-санитария гамәлләре үткәрүне, предприятиеләрнең, оешмаларның, гражданнарның

ветеринария буенча гамәлдәге кагыйдәләрне үтәүләрен тикшереп тору;

- ветеринариядә биология, химия препаратларын һәм башка препаратларны куллану, хайваннарны табигый һәм техноген бәлаказалар аркасында килеп чыккан гадәттән тыш зарарлы йогынтылардан саклау буенча махсус чаралар күрү тәртибен билгеләү;

- ветеринария-санитария буенча хокук бозуларны чикләү һәм аларны кылган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү.

2. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә әлеге Законның 5 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән урындагы затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9 статья. Баш дәүләт ветеринария инспекторы хокуклары

Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы, шәһәрләрнең һәм районнарның баш дәүләт ветеринария инспекторлары һәм аларның урынбасарлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1. Татарстан Республикасының ветеринария буенча законнары үтәлешен тикшерү, үләткә каршы чаралар, ветеринария-санитария гамәлләре үткәрүне һәм ветеринариянең гамәлдәге кагыйдәләре үтәлешен тикшерү максатында тоткарлыксыз /эш таныклыгын күрсәтеп/ предприятиеләргә һәм оешмаларга йөреп тикшерү үткәрергә.

2. Үләткә каршы чаралар һәм ветеринария гамәлләре үткәрү турында һәм ветеринария буенча хокук бозуларны бетерү хакында предприятиеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга таләпләр куярга һәм бу таләпләрнең үтәлешен тикшереп торырга.

3. Хайваннар арасында йогышлы авырулар килеп чыгуның һәм таралуның һәм терлекчелек продукциясенең ветеринария таләплә-

рено туры килмэвенең сэбэплэрен һәм шартларын ачыкларга һәм күрсәтергә.

4. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына түбәндәге тәкъдимнәрне кертә алалар:

терлекләр арасындагы үләткә каршы билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш комиссия төзү турында;

аерым территорияләрдә терлекләр арасында йогышлы авыруларны бетерүгә һәм аның таралуын булдырмауга каршы юнәлдерелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү;

предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасының ветеринария турында законнары бозылган очракта, ветеринария кагыйдәләре, дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының аларның эшчәнлеген туктатып тору яисә туктату турында карарлары үтәлмәгәндә, әлеге предприятиеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның хуҗалык эшчәнлеген туктатып тору турында.

5. Терлекләр арасындагы үләт билгеләренә карап профилактика өчен вакцинация ясау турында карар кабул итәргә.

6. Тиешле гамәлләрне үткәргәнче һәм ветеринария-санитария ягыннан хокук бозуларны бетергәнче терлекчелек продукциясен җитештерүне, саклауны, ташуны һәм сатуны туктатып торырга.

7. Әлеге Законның УП бүлеге нигезендә урындагы затларны һәм гражданнарны административ җаваплылыкка җәлеп итәргә.

10 статья. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затлар эшчәнлегенең төп гарантияләре

I. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затлар үз эшчәнлекләрендә бәйсез һәм бары тик гамәлдәге ветеринария буенча законнарга гына таянып эш итәләр.

2. Дәүләт органнары, урындагы затлар, предприятиеләр, иҗтимагый оешмалар һәм гражданнар тарафыннан дәүләт ветеринария

күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затларга аларның законлы эшчәнлегенә каршылык күрсәтү максатында йогынты ясалганда, алар Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә җавапка тартылалар.

11 статья. Җитештерү буенча ветеринария-санитария күзәтчелеге

Җитештерү буенча ветеринария хезмәте булган предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә ветеринария кагыйдәләренең үтәлешенә җитештерү буенча ветеринария-санитария күзәтчелеге ветеринария-санитария күзәтчелеге турында гамәлдәге нигезләмәгә таянып әлеге хезмәтләр тарафыннан башкарыла.

## IУ бүлек

## Терлекләр авыруларын булдырмау һәм аларны бетерү, терлекчелек продукциясенең ветеринария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча гомуми таләпләр

12 статья. Терлекчелек продукциясен җитештерүче предприятиеләрне планлаштыру һәм төзү

1. Терлекчелек комплексларын, кошчылык фабрикаларын, ит комбинатларын, терлекчелек продукциясен җитештерүче башка сәнәгать предприятиеләрен һәм шәхси крестьян /фермер/ хуҗалыкларын планлаштырганда һәм төзегәндә терлекләр тоту һәм югары сыйфатлы терлекчелек продукциясе җитештерү өчен уңайлырак шартлар булдыру, табигый тирәлекне җитештерү калдыклары белән пычратудан һәм терлекләр арасында йогышлы авырулар китереп чыгара торган пычратулардан кисәтү күздә тотылырга тиеш.

2. Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм саклау буенча предприятиеләр төзү өчен җир кишәрлекләре бирү, аларны төзү һәм файдалануга тапшыру документы проектын раслау бары тик аларның ветеринария таләпләренә туры килүләре турында дәүләт ветеринария

күзәтчелеге органнарының бәяләмәләре булганда гына рөхсәт ителә.

I3 статья. Терлекләрне асрау, ашату һәм эчертү, аларны күчерү яисә куу.

I. Терлекләрне вакытлыча яисә даими асрау өчен билгеләнгән биналар мәйданнары һәм җиһазланыш ягыннан терлекләрнең сәламәтлеге өчен уңайлы булырга тиеш.

2. Терлек асраучы предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар билгеләнгән таләпләр нигезендә аларны азык һәм су белән тәэмин итәргә тиеш.

Билгеләнгән таләпләргә җавап бирми торган терлек азыгы һәм аңа өстәмәләр баш дәүләт ветеринария инспекторы карары нигезендә җитештерүдән яисә сатудан алына.

3. Терлекләрне күчерү яисә куу дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнары белән килешенгән юнәлештә һәм терлек авырулары килеп чыгуын һәм таралуын кисәтү таләпләрен үтәп башкарылырга тиеш.

I4 статья. Татарстан Республикасы территориясен Татарстан Республикасыннан читтән терлек авырулары керүдән саклау

Татарстан Республикасына, Татарстан Республикасының ветеринария буенча законнары таләпләрен һәм Татарстан Республикасы белән чит дәүләтләр арасында төзелгән килешүләрдә каралган шартларны истә тотып, сәламәт терлекләр, шулай ук сәламәт терлекләрдән һәм йогышлы авырулар буенча имин саналган дәүләтләрдән алынган терлекчелек продукциясе генә кертелергә тиеш.

Предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар Татарстан Республикасыннан читтән терлекләрне һәм терлекчелек продукциясен Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә алалар.

**15 статья.** Терлекчелек продукциясен әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу һәм сату

Терлекчелек продукциясе ветеринария-санитария тикшерүе нәтиҗәләре буенча кеше өчен куркынычсыз һәм зарарсыз булуы турындагы билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә һәм терлекләрнең йогышлы авырулары буенча имин территориядән кайтартылырга тиеш.

Шартнамәләр төзү, терлекчелек продукциясен әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу һәм сату белән шөгыльләнүче предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар билгеләнгән таләпләрне үтәргә тиеш.

**16 статья.** Дәүләт идарәсе органнарының һәм дәүләт ветеринария хезмәте урындагы затларының йогышлы авырулар чыганакларын бетерү буенча вазыйфалары

1. Аерым территорияләрдә һәм торак пунктларында терлекләрнең йогышлы авырулары һәм күпләп йогышсыз авырулары килеп чыкканда, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, шәһәрләрнең һәм районнарның башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт ветеринария хезмәте күрсәтмәсе буенча карантин яисә башка чикләүләр кертелә.

Терлекләрнең күпләп авыруларын булдырмау һәм аларны бетерү буенча предприятиеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның эшчәнлегенә ашыгыч җитәкчелек итү һәм аны җайга салу өчен дәүләт идарәсенең күрсәтелгән органнары билгеләнгән тәртиптә терлекләр арасындагы үләткә каршы гадәттән тыш комиссияләр төзиләр.

2. Дәүләт ветеринария хезмәтенең урындагы затлары терлекләрнең күпләп авырулары чыганакларын бетерү буенча Татарстан Республикасының ветеринария законнарында каралган махсус чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр.

3. Дәүләт ветеринария учреждениеләре, җитештерү буенча ветеринария хезмәте белгечләре терлек үләксәләрен файдалануны

һәм аларны юк итүне шулай ук түләмәдән /сибирская язвадан/ үлгән терлекләрне күмү урыннарының ветеринария-санитария торышын тикшереп торырга тиешләр.

**17 статья.** Терлек хуҗаларының, алардан файдаланучыларның һәм терлек продукциясе җитештерүчеләрнең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

1. Терлек хуҗалары һәм терлекчелек продукциясе ияләре түбәндәгеләргә хокуклы:

терлекләренә ветеринария хезмәте күрсәттерүгә; терлек ризыгының туклану һәм башкача файдалану өчен яраклылыгы турында бәяләмә алырга; базарда терлек сатып алганда ветеринария таныклыгын күрсәтүне таләп итәргә.

2. Терлек хуҗалары һәм терлекчелек продукциясе ияләре түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

терлекчелек биналарын, терлекчелек ризыкларын эшкәртү, саклау һәм сату объектларын төзү һәм аннан файдалану өчен баш дәүләт ветеринария инспекторының рөхсәтен алырга;

яңа кайтарылган /сатып алынган/ барлык терлекләрне ветеринария таләпләре нигезендә аерым тотарга;

терлекләрне чит кешеләр һәм хуҗасыз хайванар белән аралашудан чикләргә;

терлекләрне хуҗалыктан читкә алып чыкканда ветеринария законнарында күрсәтелгән документларны үзе белән алырга;

терлекләрне асрауның, ашатуның һәм алардан файдалануның тиешле зоогигиена шартларын тәэмин итәргә тиеш;

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе билгеләгән ветеринария-санитария чараларын һәм терлекләр арасындагы үләткә каршы чараларны үз вакытында үткәрүне тәэмин итәргә;

терлекләрнең кинәттән үлүе яисә бер үк вакытта терлекләрнең күпләп авыруы очраклары турында хезмәт күрсәтүче ветеринария белгеченә кичекмәстән хәбәр итәргә;

ветеринария ягыннан эшкәрткәндә ветеринария белгеченә тиешле шартлар тудыруны һәм терлекләрне беркетеп куюны тәэмин итәргә;

сату өчен терлекләр суюны Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе раслаган кагыйдәләр нигезендә башкарырга;

терлек авыруларын булдырмауны тәэмин итүче һәм терлекчелек продукциясенең иминлеген тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария чаралары үткәрергә, терлекчелек калдыклары белән тирә-як мохитне пычратмаска;

терлекләр ташыганда билгеләнгән ветеринария-санитария кагыйдәләрен истә тотарга, аларны сатуны, эшкәртүне һәм алынган ризыкны сатуны ветеринария белгече рөхсәте белән генә башкарырга;

терлек авыруларына каршы профилактика, көрәш һәм ветеринариянең башка мәсьәләләре буенча чаралар турында ветеринария белгечләре күрсәтмәләрен үтәргә.

3. Терлек асраучылар һәм алардан файдаланучылар һәм терлекчелек продукциясе җитештерүчеләр хайваннарның сәламәтлеге, аларны дөрес тукландыру, асрау һәм файдалану өчен, шулай ук куркынычсыз һәм зарарсыз терлекчелек продукциясе җитештерү өчен җаваплы булалар.

<u>18 статья.</u> Терлекләрне һәм терлекчелек продукциясен хуҗаларыннан алу

Йогышлы авырулар ягыннан имин булмавы билгеле булган терлекләр баш дәүләт ветеринария инспекторы карары буенча хуҗаларыннан алынырга мөмкин.

Авыру терлекләрне яисә терлекчелек продукциясен хуҗаларыннан алу рөхсәт ителгән авырулар исемлеген Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы билгели.

Терлекләрне яисә терлекчелек продукциясен тартып алу нәтиҗәсендә зыян күргән предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар баш дәүләт ветеринария инспекторы күрсәтмәсе буенча, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган Нигезләмәгә таянып, дәүләт бюджеты исәбеннән зыянны каплатырга хаклы.

## У бүлек

### Гражданнар сәламәтлеген кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан һәм азык белән агуланулардан саклау

19 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәтенең вәкаләте

Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәте терлекчелек продукцияләрен ветеринария-санитария ягыннан тикшерә, кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан, шулай ук ветеринария-санитария ягыннан имин булмаган терлек ризыгы аша агулануулардан /зарарлануулардан/саклауга юнәлтелгән махсус башка гамәлләр үткәрә.

20 статья. Терлекчелек продукциясен ветеринария-санитария ягыннан тикшерү

Ит, суйган терлек ите һәм башка ризыклар, сөт, сөт ризыклары, йомырка, балык һәм башка төрле терлек ризыклары аларның ветеринария-санитария ягыннан иминлеген һәм туклану өчен яраклылыгын ачыклау максатларында ветеринария-санатираия тикшерүе үтәргә тиеш.

Ветеринария-санитария тикшерүен оештыру һәм үткәрү тәртибен, аның нәтиҗәләренә бәя бирү һәм терлекчелек ризыкларын туклану максатларында куллану шартлары, әлеге нәтиҗәләрдән чыгып, Татарстан Республикасының ветеринария законнарына естәмә рәвештә

чыгарыла торган ветеринария кагыйдәләре тарафыннан билгеләнә, предприятиеләр, оешмалар җитештерә торган яисә гражданнар тарафыннан базарда сатыла торган терлекчелек продукциясе әлеге кагыйдәләрдә билгеләнгән ветеринария-санитария нормативларына туры килергә тиеш.

Билгеләнгән тәртиптә ветеринария-санитария тикшерүе узмаган ит, сөт һәм башка терлекчелек ризыкларын сату һәм туклану максатларында куллану тыела.

Күн, мех, һәм башка терлекчелек чималын эшкәртү һәм куллану тәртибе гамәлдәге ветеринария кагыйдәләре тарафыннан билгеләнә.

**21 статья.** Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәте идарәсе органнарының һәм учреждениеләренең, дәүләт санитария-эпидемиология органнарының һәм учреждениеләренең Тирә-як мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән үзара мөнәсәбәтләре

Татарстан Республикасының дәүләт ветеринария хезмәте идарәсе органнары һәм учреждениеләре, дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары һәм учреждениеләре һәм Тирә-як мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган Дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәгә таянып, гражданнарның сәламәтлеген кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан саклау мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә даими рәвештә тыгыз элемтәдә булырга тиешләр.

## VI бүлек

## Татарстан Республикасының ветеринария хезмәте матди-техник тәэмин итү

**22 статья.** Ветеринария хезмәтен финанслау

1. Дәүләт бюджеты акчалары, колхозлар һәм совхозлар, агрокомбинатлар, агрофирмалар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары

һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар белән төзелгән шартнамәләр буенча башкарылган ветеринария эшләреннән керә торган хуҗалык исәбе акчалары, шулай ук бюджеттан тыш башка керемнәр: предприятиеләрнең, иҗтимагый оешмаларның, җәмгыяте хәйрия фондларының һәм аерым гражданнарның ирекле кертемнәре, ветеринария берләшмәләрен, дәүләт ветеринария хезмәте учреждениеләрен финанслау чыганагы булып тора.

2. Терлекләр арасында йогышлы авырулар таралуны кисәтү һәм аларга каршы көрәш буенча гамәлләр дәүләт ветеринария хезмәте органнары тарафыннан раслана һәм алар дәүләт бюджетыннан бүленә торган ассигнованиеләр исәбеннән башкарыла.

3. Колхозларга, совхозларга, арендачылар оешмаларына, кооперативларга, крестьян /фермер/ һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына дәүләт ветеринария хезмәте оешмалары, учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган ветеринария ярдәме, шулай ук предприятиеләрдә терлекләрне сую, терлекчелек продукциясен һәм чималын эшкәртү, әзерләү һәм саклау буенча гамәлләргә, шартнамә нигезендә түләнә.

23 статья. Ветеринария тәэминаты

1. Ветеринария учреждениеләрен, колхозларны, совхозларны, башка предприятиеләрне, оешмаларны, ветеринария кооперативларын, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче белгечләрне махсус ветеринария мөлкәте белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсенең турыдан-туры җитәкчелегендә Татарстан "Зооветснаб" республика берләшмәсе гамәлгә ашыра.

2. Ветеринария препаратлары, җиһазлары, кораллары белән үз вакытында тәэмин итү максатында һәр районда район ветерина-

214

рия берләшмәләре составында ветеринария даруханәләре ачыла.

24 статья. Ветеринария белгечләренә бирелә торган ташламалар

1. Авыл җирләренә хезмәт күрсәтүче район ветеринария берләшмәләрендә һәм дәүләт ветеринария учреждениеләрендә, колхозларда, совхозларда, төрле милек рәвешендәге башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә эшләүче югары һәм махсус урта белемле ветеринария белгечләренә, шулай ук пенсиягә киткән ветеринария белгечләренә, яшәү урынына бәйсез рәвештә, түләүсез фатирлар бирелә һәм җирле хезмәтләр күрсәтелә.

2. Ветеринария табибларына һәм фельдшерларына: өзлексез эш стажлары 5 елдан артса-хезмәт хакының 10%ы күләмендә өстәмә түләү,10 елдан артып китсә - 25%, 25 елдан артып китсә - 50% күләмендә өстәмә түләү билгеләнә.

3. Югары һәм урта авыл хуҗалыгы уку йортларын тәмамлап , колхозларга, совхозларга һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләренә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе учреждениеләренә эшкә җибәрелгән яшь ветеринария белгечләренә фатирлар чиратсыз бирелә; җыелма йорт корылмаларын, шәхси торак төзелеше өчен төзелеш материалларын беренче чиратта сату оештырыла.

## УП бүлек

## Татарстан Республикасының ветеринария законнарын бозган өчен җаваплылык

25 статья. Татарстан Республикасының ветеринария законнарын бозган өчен җаваплылык

Урындагы затлар һәм гражданнар түбәндәге хокук бозуларны кылган өчен җинаять һәм башка җаваплылыкка тартылалар:

мәҗбүри профилактика чараларын /тикшерүләрне, авыруларга каршы торучанлык чараларын-иммунизация/ үткәрүдән баш тарткан һәм аларны үткәрүнең билгеләнгән вакытын бозган өчен;

карантин кагыйдәләрен бозган өчен;

йогышлы һәм йоктырылган /инвазион/ авыруларны бетерү буенча чараларны үз вакытында һәм тулысынча үткәрмәгән өчен;

терлекләрнең йогышлы һәм йоктырылган авыруларын явыз ният белән яисә уйламыйча тараткан өчен;

авыл хуҗалыгы терлекләрен үрчеткәндә ветеринария-санитария кагыйдәләрен үтәмәү аркасында баш терлекләрнең токымсызлыгын, гинекология авыруларының таралуын һәм туганда терлекләрнең күпләп үлүен китереп чыгарган өчен;

авыл хуҗалыгы терлекләренең авыруы китереп чыгаруга сәбәп булган түбән сыйфатлы, алдан хәзерләнмәгән /зарарлы матдәләрдән арындырылмаган, җылылык, химия, биология эшкәртүе үткәрелмәгән/ азык ашатkан өчен;

махсус ветеринария белеме һәм дәүләт ветеринария хезмәтенең рөхсәте булмаган килеш ветеринария эшчәнлеге белән шөгыльләнгән өчен;

дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыручы урындагы затларга аларның законлы эшчәнлегенә комачаулык итү максатында йогынты ясаган өчен;

дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнары рөхсәтеннән башка терлекчелек фермалары, комплекслары, кошчылык фабрикалары, ит, сөт комбинатлары һәм башка объектлар планлаштырган һәм төзегән өчен;

дәүләт ветеринария инспекторларына ветеринария-санитария күзәтчелеге объектларын тикшерүне тыйган өчен;

Татарстан Республикасы территориясен чит дәүләтләрдән терлекләрнең йогышлы авырулары керүдән саклау буенча гамәлдәге законнарны, күрсәтмәләрне, кагыйдәләрне үтәмәгән, шулай ук үләткә каршы гамәлләрне һәм чик буе зонасында терлекләрне асрау һәм көтү буенча таләпләрне үтәмәгән өчен;

терлекләрне, терлекчелек ризыкларын һәм чималын, дәүләт ветеринария күзәтчелеге тикшерүендә торган башка йөкләрне халыкара /чит илгә чыгару, чит илдән кайтару, транзит/ һәм республика эчендә ташыганда /терлекләрне куалап күчергәндә/, шулай ук терлекләрнең йогышлы авыруларын кузгатучы штаммнарны, биология, химия-фармацевтика чараларын һәм башка биологик материалларны барлык төрдәге транспортта ташыганда һәм озатканда ветеринария кагыйдәләрен бозган өчен;

транспорт чараларын, контейнерларны, склад биналарын, карантин базаларын, терлекчелек йөкләрен төяү һәм бушату өчен билгеләнгән башка махсус корылмаларны, һәм ~~юдыру~~ дезинфекцияләү комплексларын тотуның ветеринария-санитария кагыйдәләрен бозган өчен халыкара диңгез һәм һава портларында, чик буе тимер юл станцияләрендә һәм автомобиль юлларында калдыкларны җыю һәм юк итү буенча ветеринария кагыйдәләрен бозган өчен;

Штраф салулар һәм башка җәзалар гаеплеләрне зыянны каплаудан азат итми.

26 статья. Дәүләт ветеринария инспекторлары куллана торган административ җаваплылык чаралары

Административ штрафлар түбәндәгечә салына:

Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе башлыгы - Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы һәм аның урынбасарлары тарафыннан урындагы затларга - 9 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, ә гражданнарга - 3 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; шәһәрләрнең һәм районнарның баш дәүләт ветеринария инспекторлары тарафыннан урындагы затларга - 6 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр һәм гражданнарга - 2 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр.

Дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының урындагы затлары тарафыннан урында штраф салынырга мөмкин;

базарларда - терлек ризыклары /шул исәптән кош һәм балык сату/, терлекчелек чималы һәм башка ашамлыклар сатуның ветери-

нария-санитария кагыйдәләрен бозган өчен;

автомобиль юлларында һәм башка юлларда, терлекләрне куу юлларында терлекләрне /шул исәптән юшларны, балыкларны һәм умарталарны/, терлекчелек продукциясен һәм чималын ташуның ветеринария-санитария кагыйдәләрен бозган өчен, шулай ук терлекләрне куу кагыйдәләрен бозган өчен.

Административ хокук бозулар өчен штраф суммасының 50% күләмендәге акчалары районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләренә бирелә дип билгеләргә.

УШ бүлек

Халыкара шартнамәләр

27 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә әлеге Законда каралган кагыйдәләрдән аерыла торган кагыйдәләр билгеләнгән булса, ул очракта халыкара шартнамәдәге кагыйдәләр кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 13 июле
№ 1934-XП